СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2024 г. Заинск № 370

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2011 елның 8 апрелендәге 63 номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык һәм индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен гражданнарга милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь һәм максималь чик күләмнәрен билгеләү турында» карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 7 маендагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Советының 2011 елның 8 апрелендәге 63 номерлы «Шәхси ярдәмче хуҗалык һәм индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен гражданнарга милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең минималь һәм максималь күләмнәрен билгеләү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Советының Экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, ТКХ һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**